**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 июнь № 396

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче һәм 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8. | Мәдәниятне үстерү | Татарстан Республикасы Мәдә- | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак- | Мәдәният өлкәсен модернизацияләү; һөнәри сәнгатьне үстерү; республиканың |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ният министрлыгы | коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, «Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасының халык сәнгате һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү үзәге, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләре | бердәй мәдәни киңлеген ныгыту; эстетик тәрбия системасын камилләштерү; сәләтле балаларга һәм иҗади яшьләргә ярдәм күрсәтү; мәдәни мирас объектларын саклап калу, һәркем алырлык булуын күтәрү, популярлаштыру һәм саклау; халык сәнгате һөнәрләрен саклау, торгызу, өйрәнү һәм үстерү; китапханә эшен үстерү һәм китапханә фондларының һәркем файдалана алырлык санлы контентын булдыру; дәүләт музейларын һәм республиканың музей-тыюлыкларын, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләрен саклау һәм үстерү; Татарстан Республикасы музей фондының саклanышын тәэмин итү; фильмнар фондларын саклауны, тулыландыруны һәм файдалануны тәэмин итү, Россиянең уникаль истәлекле урыннарын: Свияжск утрау-шәһәрен һәм борынгы Болгарны саклауны һәм нәтиҗәле куллануны, аларны рухи, социаль-икътисадый һәм мәдәни торгызуны тәэмин итү; кинематографияне үстерү һәм аңа ярдәм итү, кинематография әсәрләреннән һәркем файдалана алсын өчен шартлар тудыру; мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә грантлар белән ярдәм итүне гамәлгә ашыру; мәдәният |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү; татар телен, әдәбиятка керешне һәм сәнгать белемен актуаль фундаменталь һәм кулланма тикшеренүләр үткәрү»; |

Исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 33 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «33. | Архив эшен үстерү | Татарстан Республикасының архив эше буенча комитеты | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | Хакимиятнең хәбәрдарлыгын күтәрү, җәмгыятьнең дәүләт идарәсендә катнашуын хуплау, демократия нигезләрен ныгыту максатларында дәүләт идарәсенең аеручы әһәмиятле документлары белән ачык файдалана алуны тәэмин итү; архив эше өлкәсендә, эчке һәм тышкы контурларда, шул исәптән социаль челтәрләрдә архив сервисларының клиентка таба юнәлеш алуында дәүләт хезмәтләренең сыйфатын һәм файдалана алырлык булуын күтәрү; архив документларын эзләү, тикшерү һәм өйрәнү өчен, шул исәптән аларны цифрлау юлы белән, һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү; архив фонды документларын фәнни әйләнешкә кертү, Татарстан Республикасы Архив фонды һәм башка архивлар документларын, шул исәптән төбәкара һәм халыкара элемтәләрдә тулысынча куллануны тәэмин итү; Татарстан Республикасында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | архив эше белән идарә итү системасы бизнес-процессларының һәм ресурсларның, шул исәптән кадрлар белән тәэмин ителешнең нәтиҗәлелеген күтәрү; электрон документлар әйләнешенә күчү контекстында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эш башкару системасын үзгәртеп төзү һәм яңарту;<br>фондларны чыганакларның һәм мәгълүмат йөртү җайланмаларының эволюциясен исәпкә алып сыйфатлы һәм бөтенесен эченә алган комплектлау, шул исәптән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында электрон документлар әйләнеше системасы үсеше кысаларында;<br>дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында мәгълүмат ресурсларының саклануын һәм тулылыгын тәэмин итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков